**КАРАР**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ХУҖӘМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

25.09.2018 № 1

**Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге" башкарма комитетының 2018 елның 17 сентябрендәге №37 карары нигезендә

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2018 елның 18 ноябренә Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез килешәсезме:

1. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-ике обелисклы билгесез солдат һәйкәлен ремонтлау һәм һәйкәл тирәсендәге территорияне төзекләндерү,

Хуҗәмәт, Усай , Яңа Александровка, Бакчасарай торак пунктларында мәгълүмати стендлар әзерләү һәм урнаштыру.

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Яңа Александровка торак пунктына юл салу.

3. Җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә:

-Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү, бәйрәмнәр әзерләү һәм уздыру.

4. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

-Бакчасарай торак пунктында тирән насосны сатып алу һәм урнаштыру, су башнясы территориясен тәртипкә китерү

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Хуҗәмәт авылы, Мирная урамы 72 нче йорт, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайты menzelinsk.tatarstan.ru адреслары буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы: Вильданова Г.Г.